ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 сентябрь 2017 ел № 5325

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 19.12.2016 елның 19 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне планлаштыру һәм территорияләрне комплекслы һәм тотрыклы үстерүне тәэмин итү буенча документларны әзерләүне һәм раслауны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2016 елның 3 июлендәге 373-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 31 июлендәге 4534 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2015 елның 31 декабрендәге 7629 номерлы, 2016 елның 28 июнендәге 3311 номерлы карарлары редакциясендә) расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Төзелеш Министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр боерыгы белән (рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru (13.04.2015);»

2) 1.4 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары нигезендә (алга таба –Муниципаль хезмәтләр);»

3) 1.4 пунктының 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);»;

4) 2.4, 2.5, 2.6, 2.9 пунктларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә редакциядә;

5) 2.16 пунктында «яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» сүзләреннән соң «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен өстәргә;

6) 3.1.2 пунктында «3 нче кушымта» сүзләрен «5 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

7) 3.3.1 пунктында беренче абзацта «идарәгә» сүзеннән соң «Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) сүзләрен өстәргә»;

8) 3.3.1 пунктында икенче абзацта «Башкарма комитетның» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 3.3.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2 Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гамәлгә ашыра:»;

10) 3.3.2 пунктында алтынчы абзацта «идарә белгече» сүзләрен «эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече» сүзләренә алмаштырырга;

11) 3.3.2 пунктында унынчы абзацта «идарә белгече» сүзләрен «эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече» сүзләренә алмаштырырга;

12) 3.3.2 пунктында 13 абзацында «бер көн» сүзен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

13) 3.3.3 пунктында беренче абзацта:

- «гариза» сүзенә алмаштырырга;

- «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына (архитектура, төзелеш) (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары)» сүзләрен «идарә башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

14) 3.3.3 пунктында икенче абзацта «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләрен «идарә башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

15) 3.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.4. Идарә башлыгы тапшырылган гаризаны, документларны карап тикшерә һәм ЭДӘ аша башкаручыга- идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза һәм документлар.»;

16) 3.4 пунктында «органнары» сүзеннән соң «(оешмалар)» сүзе өстәргә;

17) 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

18) «3.4.1. Идарә белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар (мәгълүмат) бирү турында ведомствоара запрослар (кәгазьдәге документ яки электрон документ рәвешендә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар идарә белгеченә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат белән тәэмин итүчеләргә җибәрелгән ведомствоара запрослар.»;

19) 3.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, кергән ведомствоара запрослар нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүмат) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе (алга таба – документ (мәгълүмат) булмау турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мәгълүмат белән тәэмин итүчегә ведомствоара запрос кергән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрү федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәгән булса.

Гариза бирүчегә җир участокларына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү, җир участогы төзү турында белдерү кәгазе кергән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мәгълүмат белән тәэмин итүчегә ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Мәдәни мирас объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында гариза кергән очракта, шулай ук тарихи җирлек территориясе чикләрендә төзелешкә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында гариза кергән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мәгълүмат белән тәэмин итүчегә ведомствоара запрос кергән көннән башлап егерме биш көн эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәгән булса.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яки документ (мәгълүмат) булмавы турында белдерү кәгазе.»;

20) 3.5.1 пунктында икенче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

21) 3.5.1 пунктында өченче абзацта «әзерләнгән документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

22) 3.5.1 пунктында дүртенче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

23) 3.5.1 пунктында бишенче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

24) 3.5.2 пунктында беренче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

25) 3.5.2 пунктында икенче абзацта «өч көн» сүзен «ике эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

26) 3.5.2 пунктында өченче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

27) 3.6.1 пунктында икенче абзацта «документның» сүзен «карарның» сүзенә алмаштырырга;

28) 3.6.1 пунктында дүртенче абзацта «документлар» сүзен «карар проектлары» сүзенә алмаштырырга;

29) 3.6.2 пунктында дүртенче абзацта «бер көн» сүзен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

30) 3.8.2 пунктында икенче абзацта «башлап бер көн эчендә» сүзләрен «көнне» сүзенә алмаштырырга;

31) 3.8.3пунктының икенче абзацында:

- «АШТһТҮИ» сүзен «идарә» сүзенә алмаштырырга;

- «документ» сүзен «муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документ» сүзләренә алмаштырырга;

32) 3.8.3 пунктында өченче абзацта «өч көн» сүзен «өч эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

33) 3.8.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документ.»;

34) 4.2 пунктында «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «идарә башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

35) 4.4 пунктында «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «идарә башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

36) Регламентка 1 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

37) Регламентка 2 нче кушымтаны әлеге карарга 3 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

38) Регламентка 3 нче кушымтаны әлеге карарга 4 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

39) Регламентка 4 нче кушымтаны әлеге карарга 5 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

40) Регламентка 5 нче кушымтаны әлеге карарга 6 нчы кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

41) Регламентка 6 нчы кушымтаны әлеге карарга 7 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

3. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
1 нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | 1) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән башлап җиде эш көне эчендә (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);<br>2) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза алган көннән башлап җиде эш көне эчендә (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);<br>3) техник хатаны төзәтү турында гариза алган көннән башлап өч эш көне эчендә (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);<br>4) җир участокларына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы гариза бирүчегә күчү, җир участогы төзү турында белдерү кәгазе алганнан соң ун эш көне эчендә (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);<br>5) гариза алынганнан соң утыз көн эчендә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 11.1 пунктында күрсәтелгән очракта) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта). | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 11 өлеше<br><br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.14 өлеше<br><br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.14 өлешенең 3 пункты |
| 2.5. Муниципаль хезмәт, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Капиталь төзелеш объектларын (шул исәптән мәдәни мирас объектын, капиталь төзелеш объектларын федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә төзү, реконструкцияләү планлаштырылган очракта) төзү, реконструкцияләү максатларында төзүче тапшыра:<br>1) гариза;<br>2) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ 4) җир участогына хокук билгели торган документлар, әгәр аңа хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәмәгән булса);<br>5) Россия Федерациясе бюджет законнары, дәүләт хакимият органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлеше<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеше<br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.13 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән очракларда бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешү;<br>6) аның белән күрсәтелгән килешү төзелгән җир участогына хокук иясенең хокук билгеләүче документлары;<br>7) проект документларындагы материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) капиталь төзелеш объектының урнашу урынын, аңа килүче юлларны, җәмәгать сервитутларының гамәлдә булу зонасының чикләрен, археологик мирас объектларын күрсәтеп, җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы;<br>в) линияле объектның линия объектларына карата территорияне планлаштыру документлары составында расланган кызыл линия чикләрендә урнашуын раслый торган җир участогын планлаштыру схемасы;<br>г) архитектура чишелешләре;<br>д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүматлар, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләп, инженер-техник тәэмин итү челтәрләрененең җыелма планы;<br>е) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;<br>ж) капиталь төзелеш объектын, аның өлешләрен сүтеп алу яки демонтажлау буенча эшләрне оештыру проекты;<br>з) шулай ук инвалидларның сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт объектларына һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына капиталь төзелеш объектына | |

| | | |
|---|---|---|
| | керүен тәэмин итү буенча чаралар исемлеге, күрсәтелгән объектлар төзелгән һәм реконструкцияләнгән очракта һәм әлеге объектларның проект документларына экспертиза РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә үткәрелмәгән булса;<br>8) капиталь төзелеш объектының проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр мондый проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза уздырылырга тиеш булса;<br>9) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракта проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе;<br>10) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракта проект документларына уңай экологик экспертиза бәяләмәсе;<br>11) модификацияләнгән проект документларыннан файдаланган очракта әлеге Кодексының 49 статьясындагы 3.5 өлешендә каралган бәяләмә;<br>12) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, әлеге пунктның 9 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш;<br>13) реконструкцияләү дәүләт хакимият органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы булып исәпләнгән дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан хокук иясе дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе булган, аңа карата күрсәтелгән орган гамәлгә куючы яки милек хуҗасы хокуклары функцияләре һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт (муниципаль) бюджет яки автономияле | |

| | | |
|---|---|---|
| | учреждениесенең дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында үткәрелгән очракта - мондый реконструкцияләүне үткәрү турында реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка салынган зыянны каплауның шартлары һәм тәртибен билгеле торган килешү;<br><br>14) күпфатирлы йорт реконструкцияләнгән очракта күпфатирлы йортта биналар һәм машина-урыннары милекчеләренең торак законнары нигезендә кабул ителгән гомуми җыелышы карары яки, әгәр мондый реконструкцияләү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме кимесә, күпфатирлы йорттагы барлык биналар һәм машина-урыннары милекчеләренең ризалыгы;<br>15) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турындагы таныклык күчермәсе, әгәр дә проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән булса;<br>16) әгәр мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар.<br>Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү максатларында төзүче тарафыннан бирелә:<br>1) гариза;<br>2) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>4) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән очракта, җир участогына хокук билгеле торган документлар;<br>5) индивидуаль торак төзелеше объектын урнаштыру урынын күрсәтеп, җир участогын планлаштыру схемасы;<br>6) индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы күренешен тасвирлау (әгәр дә индивидуаль торак төзелеше | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 9 өлеше<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса, РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 10.2 өлешендә каралган очрактан тыш).<br>Капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү типлаштырылган архитектура карары нигезендә планлаштырылса, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризада шундый типлаштырылган архитектура карары күрсәтелә. Бу очракта объектның тышкы күренешен тасвирлау кушымтасы таләп ителми.<br>Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертелгән очракта, төзүче тарафыннан бирелә:<br>1) гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиле вәкаләтләренраслый торган документ;<br>4) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертүне нигезләүче документ.<br>Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта-:<br>1) әлеге Регламентка гариза (№3 кушымта);<br>2) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>4) техник хатаны үз эченә алган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документ.<br>Гариза бирүчегә җир участокларына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкән очракта, җир участогын төзү турында гариза бирүче тарафыннан, реквизитлар күрсәтеп, белдерү (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) бирелә: | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 10.2 өлеше<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеше<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеше<br><br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.11 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 1) РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.5 өлешендә күрсәтелгән очракта, мондый җир участокларына хокук билгели торган документлар;<br>2) РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир участокларын төзү турында карар, әгәр җир законнары нигезендә җир участогын төзү турында карар дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителсә;<br>3) РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.6, 21.7 өлешендә каралган очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган җир участогының шәһәр төзелеше планы;<br>4) РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6 Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы | 1) юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2) күчемсез милек объектына (җир участогына) төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында бердәм дәүләт хокук реестрыннан өземтә;<br>3) бердәм дәүләт хокуклар реестрыннан күчемсез милек объектына (җир участогындагы капиталь төзелеш объектларына) төп характеристикалар турында өземтә;<br>4) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр өч | РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясының 7.1, 9.1 өлешләре |

| | | |
|---|---|---|
| һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | елдан да иртәрәк бирелмәгән җир участогының шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (2017 елның 1 гыйнварына кадәр расланган җир участогының шәһәр төзелеше планнарын куллану сроклары турында), 2016 елның 3 июлендәге 373-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1, 2, 3 өлешләрен карагыз);<br><br>5) рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкциянең чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт (әгәр төзүчегә мондый рөхсәт РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 40 статьясы нигезендә бирелгән булса);<br>6) РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 48 статьясындагы 12 өлешнең 3 пунктында яки РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 9 өлешнең 4 пунктында каралган проект документларының, тарихи җирлекне саклау предметына һәм федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше Регламенты тарафыннан билгеләнгән архитектура карарларына карата таләпләргә туры килмәве турында Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы бәяләмәсе (әгәр дә линияле объект булып саналмый торган һәм аны төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирүгә гариза бирелгән булса). | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;<br>2) тапшырылган документларның капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата, шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу өчен бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планы төзелешенә рөхсәт бирелгән көнгә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве; | РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясы;<br><br>РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясының 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә туры килмәве (линияле объектны төзүгә рөхсәт бирелгән очракта);<br>4) тапшырылган документларның җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве;<br>5) тапшырылган документларның рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкциянең чик параметрларыннан читләштерүгә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>6) мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарыннан кергән, капиталь төзелеш объектының проект документларының бүлегенең яки индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы кыяфәтен тасвирлауның тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты белән федераль яки региональ әһәмияттәге территориаль зонага карата билгеләнгән архитектура карарларына туры килмәве турында бәяләмә<br>7) әгәр тиешле документ гриза бирүче тарафыннан тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара запроска җавап килүе. | |
| | Төзелешкә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1) белдерү кәгазендә җир участогына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук күчүе, җир участогын төзү турында РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.10 статьясындагы 1 - 4 пунктларында каралган документлар реквизитлары булмау яисә РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта җир участогына хокук билгели торган документ булмау;<br>2) җир участогына хокукларны, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын күчерү, җир участогын төзү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеге; | РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясының 21.7, 21.11, 21.13 өлешләре<br><br>РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясының 21.15 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) капиталь төзелеш объектын планлаштырыла торган урнаштыру планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт бирелгән җир участогыннан файдалану һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә карата РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган таләпләргә туры килмәве.<br><br>Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтне озайтудан баш тартыла:<br>1) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтне озайту турында гариза аның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы алтмыш көннән дә кимрәк вакыт эчендә тапшырылса;<br>2) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау капиталь төзелеш объектын төзүгә һәм реконструкцияләүгә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы алтмыш көннән дә ким булмаган вакыт эчендә башланмаса;<br>3) төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча торак урынын тапшыру буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәве яки күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын (төзүче) өлешләп төзү өчен акча җәлеп итүче затның (төзүче) граждан җаваплылыгын иминләштерү шартнамәсе, торак урынын өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча тапшыру йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен банк поручительлеге шартнамәсе теркәлмәгән (өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе нигезендә төзелгәндә). | РФ шәһәр төзелеше Кодексының 51 статьясының 20 өлеше |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
2 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
___________________________________
(Ф.И.А.и.)
___________________________________
___________________________________
___________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш)
___________________________________
___________________________________
(почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы)

## Гариза

Сездән
________________________________________________________________________
(шәһәр, район, урам, участокның номеры)
буенча урнашкан ______________________________кадастр номерлы җир участогында
________________________________________________________________________
(барлык төзелеш-монтаж эшләрен, аерым эш төрләрен,
________________________________________________________________________
әзерлек эшләрен алып баруга рөхсәт – кирәклесен сызарга, объектның исеме)
________________________________________________________________________
______________________________срокка рөхсәт бирүегезне сорыйм.
Шул ук вакытта хәбәр итәм:
1) Җир участогына хокук билгеләүче (хокук раслаучы) документ ________________________________________________
«__» _________ 20__ ел № _______________;
2) объектны төзүгә проект документлары __________________________________
________________________________________________________________________
(проект оешмасының исеме,
________________________________________________________________________
лицензия биргән лицензион үзәкнең исеме)
20__ елның «__» __________ ______________номеры белән эшләнгән һәм тиешле тәртиптә архитектура һәм шәһәр төзелеше оешмалары һәм органнары белән килештерелгән;
3) дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе 20__ елның «__»_________ __________ номеры белән алынган;

4) җир участогының генераль планы
______________________________________________________________________
(җир участогының генераль планын биргән органның исеме)
20__ елның «__» _________ _____________номеры белән әзерләнгән;
5) проект ______________________________________________________
(оешманың исеме)
тарафыннан 20__ елның «__» _________ ______________номерлы приказ белән расланган.

Бер үк вакытта Сезгә түбәндәгеләр турында хәбәр итәм:
а) төзелешне финанслау заказчы (төзүче) тарафыннан башкарылачак
___________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)
б) эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылачак
_____________________________________________________________________________________
(милек формасын һәм банк реквизитларын күрсәтеп оешманың исеме).
___________________________________________________________________________
Төзелеш-монтаж эшләрен алып бару хокукына документлар
___________________________________________ 20__ елның «__» _______
______________номеры белән бирелгән;
(оешманың исеме)
в) 20__ елның «__» _________ _________номерлы приказ белән
эшләрне башкаручы итеп ________________________________________билгеләнгән,
____________________________
(вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (югары, урта)
һөнәри белемле, төзелештәге эш стажы ___________ ел;
г) автор күзәтчелеге 20__ елның «__» ________ ____номерлы шартнамә нигезендә
__________________________________________________________________________
банк реквизитлары белән оешманың исеме
__________________________________________________________________________
башкарылачак,
(хезмәткәрнең вазыйфасы, Ф.И.А.и., телефон номеры)
20__ елның «__» ________ ____________ номерлы приказ белән билгеләнгән,
______________________________ һөнәри белемле
(югары, урта)
һәм төзелеш һәм проектлаштыруда эш стажы __________ ел;
д) техник күзәтчелек 20__ елның «__» ________ ____номерлы шартнамә нигезендә
__________________________________________________________________________
банк реквизитлары белән оешманың исеме
__________________________________________________________________________
башкарылачак,
(хезмәткәрнең вазыйфасы, Ф.И.А.и., телефон номеры)
20__ елның «__» ________ ____________ номерлы приказ белән билгеләнгән,
______________________________ һөнәри белемле
(югары, урта)
һәм төзелеш һәм проектлаштыруда эш стажы ____________ ел.
Объектның төп күрсәткечләре: ______________________________________________
___________________________________________________________________________

Әлеге гаризадагы мәгълүматлар белән бәйле барлык үзгәрешләр һәм мәҗбүри нормаларны һәм регламентларны бозулар турында Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә хәбәр итәргә йөкләмә алам.

Заказчы (төзүче)

____________________________ _________________ _________________________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)

М.У.

Документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече кабул итте

___________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
3 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесенә

_________________________________
(Ф.И.А.и.)
_________________________________
_________________________________
_________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш)

_________________________________
_________________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы)

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә,
реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында
гариза

______________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының исеме һәм адресы)

объекты буенча 20______елның «__» ________ __________номерлы капиталь төзелеш объектларын төзүгә,

реконструкцияләүгә рөхсәткә

____________________________________________________________

______________________________________________________________________
(үзгәрешләр кертүнең сәбәпләрен һәм документ реквизитларын күрсәтеп)

бәйле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Кушымта:

1. ____________________________________________________________
2. ____________________________________________________________

(гаризага теркәлә торган документларның исемлеге)

_____________________ _____________ _____________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)

«__» ___________ 20__ ел
М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
4 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
_______________________________________
(Ф.И.А.и.)
_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш)
_______________________________________
_______________________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________
(муниципаль хезмәтнең исеме)
Язылган:____________________________________________________________
______________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: _______________________________________________
______________________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.
Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:
электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән
кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне: ______________________________________________________________________.
Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси

белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

__________________________ _______________ __________________________________

(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)

«__» __________ 20__ ел.
М.У.

М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
5 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесенә

______________________________________
(Ф.И.А.и.)
______________________________________
______________________________________
______________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш)

______________________________________
______________________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы

Җир участогына (участокларына) хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазе

________________________________________________________________
________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының исеме һәм адресы)
объекты буенча 20_______елның «__» _________ ___________номерлы төзелешкә
рөхсәткә _______________________________________________________________
____________________________________________________________________________

(сәбәпләрне һәм Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.10 өлешнең 1,2, 3 пунктларында күрсәтелгән документ реквизитларын күрсәтеп)
бәйле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Кушымта:
1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________
(гаризага теркәлә торган документларның исемлеге)

______________________ ______________ ___________________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)

«__» ____________ 20__ ел
М.У.

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
6 нчы кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм
аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының
телефоннары


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы | 30-55-08 | gradoctroitel@mail.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 11 сентябрендәге
5325 номерлы карарына
7 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

муниципаль хезмәт күрсәтүнең
БЛОК-СХЕМАСЫ



Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр тарафыннан идарә белгеченә запросларга документлар (мәгълүмат) җибәрү

идарә белгеченә җибәрелгән документлар

идарәсе белгече тарафыннан карар проектын әзерләү:
1) КТО төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт проекты яисә
2) КТО төзелешенә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат проекты һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен карар проекты

Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты

Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карар проектын имзалау һәм аны Идарә белгеченә җибәрү

Башкарма комитет Җитәкчесе имзалаган карар проекты

Идарә белгече тарафыннан карар проектын теркәү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе турында хәбәр итү

Теркәлгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе

Идарә белгече тарафыннан гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү яисә аны почта аша җибәрү

Гариза бирүчегә бирелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова